ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

04.09.2015 г.Казань № 106

**Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау хакында**

2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 172-ФЗ номерлы Федераль закон, 2009 елның 24 декабрендәге “Аерым норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, шулай ук коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Рәис С.Е.Иванов

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2015 елның
04 сентябрендәге № 106
боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) 2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 172-ФЗ номерлы Федераль закон, 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы (алга таба – Методика), 2009 елның 24 декабрендәге “Аерым норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенраслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 883 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан эшләнә торган норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына, Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнә торган норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрүне дә кертеп, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Коррупциягә каршы экспертиза Дәүләт комитетының эшләнә торган норматив-хокукый актлары проектларына (алга таба – норматив-хокукый актларның проектлары) хокукый экспертиза үткәргәндә һәм Дәүләт комитетының кабул ителгән норматив-хокукый актларын (алга таба – норматив-хокукый актлар) мониторинглаганда үткәрелә.

1.3. Норматив-хокукый актларда һәм норматив-хокукый актларның проектларында коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү коррупциягә каршы экспертизаның максаты булып тора.

1.4. Көчен югалткан яки гамәлдән чыгарылган норматив-хокукый актларга карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелми.

## 2. Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибе

2.1. Коррупциягә каршы экспертиза 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы (алга таба – Методика) нигезендә үткәрелә.

2.2. Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе (алга таба – рәис) Дәүләт комитетында коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җаваплы булган вазифаи затны (алга таба – вазифаи зат) билгели. Күрсәтелгән вазифаи зат Дәүләт комитетында коррупциягә каршы экспертизага тапшырылган норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналын (алга таба – Журнал) (1 кушымта) алып бару өчен җаваплы була.

2.3. Норматив-хокукый актны, норматив-хокукый акт проектын эшләгән структур бүлекчә (алга таба – эшләүче) норматив-хокукый акт проектын коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен вазифаи затка тапшыра, бу хәл ул тапшырылган көнне Журналда чагылдырыла.

Норматив-хокукый актларда аларны куллануны мониторинглаганда вазифаи зат тарафыннан коррупциоген факторлар ачыкланганда, норматив-хокукый актларда коррупциоген факторларны ачыклаган көнне Журналда теркәлә.

Норматив-хокукый актларда аларны куллануны мониторинглаганда эшләүче тарафыннан коррупциоген факторлар ачыкланганда, эшләүче норматив-хокукый актны коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен вазифаи затка җибәрә, бу хакта ул ирешкән көнне Журналда чагылдырыла.

2.4. Коррупциягә каршы экспертиза норматив-хокукый актны һәм норматив-хокукый акт проектын Журналда теркәгән көннән соң җиде көнлек срокта үткәрелә.

2.5. Норматив-хокукый актка һәм норматив-хокукый актның проектына ясалган коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча вазифаи зат тарафыннан бәяләмә әзерләнә һәм имзалана.

Коррупциоген факторлар булу турындагы бәяләмәдә (2 кушымта) Методика нигезендә үткәрелгән коррупциягә каршы экспертиза барышында ачыкланган коррупциоген фактлар чагылдырыла һәм аларны бетерү ысуллары тәкъдим ителә.

Норматив-хокукый актларда һәм норматив-хокукый актларның проектларында коррупциоген факторлар булмаган очракта, коррупциоген факторлар юклыгы турында бәяләмә төзелә (3 кушымта), ул эшләүчегә җибәрелә.

2.6. Экспертизага җибәрелгән норматив-хокукый акт проектында коррупциоген факторлар булмаса, эшләүче, коррупциоген факторлар юклыгы турындагы бәяләмәне алгач, норматив-хокукый акт проектын кызыксынган структур бүлекчәләрнең җитәкчеләренең имзалары белән имза салу өчен рәискә җибәрә.

2.7. Әгәр дә норматив-хокукый актта коррупциоген факторлар ачыкланса, вазифаи зат эш көне дәвамында коррупциоген факторлар булу турындагы бәяләмәне эшләүчегә җибәрә.

Эшләүче, бәяләмәне алгач, рәис белән килештереп, аңа үзгәрешләр кертү кирәклеге яки аны көчен югалткан дип тану турында карар кабул итә һәм өч көнлек срокта, ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү максатында, үзгәрешләр кертү турында проект яисә норматив-хокукый актны көчен югалткан дип тану турында проект әзерли һәм вазифаи затка коррупциягә каршы экспертизага җибәрә.

2.8. Экспертизага җибәрелгән норматив-хокукый акт проектында коррупциоген факторлар ачыкланса, эшләүче, коррупциоген факторлар булу турындагы бәяләмәне алгач, өч көн эчендә барлык җитешсезлекләрне бетерергә тиеш һәм эшләнеп бетерелгән норматив-хокукый акт проектын вазифаи затка тагын коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен җибәрә.

2.9. Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына яңадан коррупциягә каршы экспертиза өч көнлек срокта ясала.

2.10. Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре Журналда чагылдырыла.

2.11. Рәис норматив-хокукый актны, норматив-хокукый акт проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына коррупциягә каршы экспертиза ясау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә җибәрергә хокуклы.

## 3. Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү тәртибе

3.1. Дәүләт комитетының рәсми басылып чыккан һәм “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге Дәүләт комитетының рәсми сайтында (http://tourism.tatarstan.ru) (алга таба – рәсми сайт) урнаштырылган Дәүләт комитеты норматив-хокукый актлары, Дәүләт комитеты тарафыннан эшләнә торган норматив-хокукый актларның проектлары коррупциягә каршы бәйсез экспертиза объектлары була.

3.2. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларны яки конфиденциаль характердагы мәгълүматларны үз эченә алучы норматив-хокукый актларга, норматив-хокукый актларның проектларына карата үткәрелми.

3.3. Норматив-хокукый актның проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү өчен эшләүче аны вазифаи затка рәис боерыгы белән билгеләнгән норматив-хокукый актларның проектларын урнаштыру өчен җаваплы затка (алга таба – җаваплы зат) аларны вазифаи затка карап тикшерү өчен җибәрелгән көнгә туры килүче эш көне дәвамында җибәрә.

3.4. Эшләүчедән норматив-хокукый акт проектын алу көненә туры килүче эш көне дәвамында вазифаи зат аларны рәсми сайтта урнаштыра.

3.5. Норматив-хокукый актларның проектларын коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен урнаштырганда вазифаи зат эксперт бәяләмәләрен җибәрү өчен Дәүләт комитеты адресын (шул исәптән Дәүләт комитетының электрон почта адресын), шулай ук коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрне кабул итә башлау һәм тәмамлау көнен күрсәтә.

3.6. Норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү вакыты аларны рәсми сайтта урнаштырган көннән башлап

кимендә биш эш көне дәвам итә.

3.7. Норматив-хокукый актка, норматив-хокукый актның проектына карата коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча Дәүләт комитетына килгән бәяләмә (алга таба – бәяләмә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының бердәм ведомствоара электрон документ әйләнеше системасында теркәлә һәм эшләүчегә коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен җибәрелә.

3.8. Бәяләмә киңәш бирү характерына ия һәм Дәүләт комитеты тарафыннан зарури тәртиптә карап тикшерелергә тиеш. Эшләүче килгән бәяләмәне карап тикшерә һәм аны алганнан соң 15 көнлек срокта коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргән юридик яки физик затка дәлилләнгән җавап җибәрә, бәяләмәдә ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдимнәр булмаган очраклардан тыш.

3.9. Норматив-хокукый актка, норматив-хокукый акт проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәргәндә ачыкланган коррупциоген факторлар эшләүче тарафыннан Тәртипнең 3.8 пунктында билгеләнгән вакыт дәвамында бетерелә.

3.10. Кисәтүләрне бетергәннән соң һәм бәяләмәдә бәян ителгән тәкъдимнәрне исәпкә алгач, эшләүче норматив-хокукый акт проектын, яңадан коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен, коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча килгән бәяләмәләрне теркәп, вазифаи затка тапшыра. Яңадан коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өч көнлек срокта башкарыла.

3.11. Әгәр норматив-хокукый актта коррупциоген факторлар ачыкланса, эшләүче, бәяләмәне Дәүләт комитетында теркәгән көннән алып өч көнлек срокта, норматив-хокукый актка үзгәрешләр кертү турында яки аны көчен югалткан дип тану буенча чаралар күрә.

3.12. Эшләүче норматив-хокукый актларда һәм норматив-хокукый актларның проектларында коррупциоген факторлар булуны раслый торган коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, эшләүче законнарда билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән норматив-хокукый актларны, норматив-хокукый актларның проектларын, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәсен һәм үзенең ризасызлыгы нигезләнгән аңлатма язуын теркәп, коррупциягә каршы экспертиза үткәрү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрә.

3.13. Эшләүче Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы тәртибендә Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасына кертелә торган, үзе тарафыннан эшләнгән федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнары проектларында, Татарстан Республикасы указлары проектларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары проектларында коррупциоген факторлар булуны раслый торган коррупциягә каршы, шул исәптән бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, эшләүче күрсәтелгән норматив-хокукый актларның проектларын карап тикшерү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә кертә.

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының 2015 елның 04 сентябрендәге 106 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитетының норматив-хокукый актларына һәм норматив-хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү тәртибенә карата 1 кушымта

## Коррупциягә каршы экспертизага тапшырылган норматив-хокукый актларны һәм норматив-хокукый актларның проектларын исәпкә алу журналы

| № п/п | Актның (акт проектының) экспертизага тапшырылу датасы | Актны (акт проектын) эшләгән структур бүлекчә аталышы | Актның (акт проектының) аталышы | Экспертиза үткәрү вакыты | Коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәсе | Бәяләмә бирү датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | 2 | 3 | 5 | 6 | 7 |

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2015 елның 04
сентябрендәге 106 номерлы
боерыгы белән расланган
Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының норматив-
хокукый актларына һәм
норматив-хокукый актлары
проектларына коррупциягә
каршы экспертиза үткәрү
тәртибенә карата 2 кушымта

Коррупциоген факторлар булу турында бәяләмә

______________________________________________

(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты 2009 елның 17 июлендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 172-ФЗ номерлы Федераль закон, 2010 елның 26 февралендәге “Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында” 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә, коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында

______________________________________________

(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

Тапшырылган ______________________________________________

(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

түбәндәге коррупциоген факторлар ачыкланды__________________________

(коррупциоген фактор төрләре күрсәтелә)

Ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү өчен түбәндәгеләр киңәш ителә______________________________________________

(коррупциоген факторларны бетерү ысуллары күрсәтелә)

______________________ ______________ _______________________ __________

(вазифа аталышы) (имза) (инициаллар, фамилия) (дата)

Татарстан Республикасы
Туристлык буенча дәүләт
комитетының 2015 елның 04
сентябрендәге №106 боерыгы
белән расланган Татарстан
Республикасы Туристлык
буенча дәүләт комитетының
норматив-хокукый актларына
һәм норматив-хокукый актлары
проектларына коррупциягә
каршы экспертиза үткәрү
тәртибенә карата 3 кушымта

Коррупциоген факторлар юклыгы турында бәяләмә

_______________________________________________________________

(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

Татарстан Республикасы Туристлык буенча дәүләт комитеты 2009 елның 17 июлендәге "Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында" 172-ФЗ номерлы Федераль закон, 2010 елның 26 февралендәге "Норматив-хокукый актларның һәм норматив-хокукый актларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында" 96 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Норматив-хокукый актларга һәм норматив-хокукый актларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза үткәрү методикасы нигезендә, коррупциоген факторларны ачыклау һәм алга таба аларны бетерү максатларында

_______________________________________________________________

(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

карата коррупциягә каршы экспертиза үткәрелде.

Тапшырылган ___________________________________________________

(норматив-хокукый акт яки норматив-хокукый акт проектының аталышы)

коррупциоген факторлар ачыкланмады.

______________________ ______________ _______________________ __________

(вазифа аталышы) (имза) (инициаллар, фамилия) (дата)